**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 1 апреле 456/ПИК номер

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 09 апрелендәге 800 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән юридик затларга җир кишәрлекләрен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлеше нигезендә карар бирәм:

1. Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 09 апрелендәге 800 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән юридик затларга җир кишәрлекләрен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты үз көчен югалткан дип танырга.
2. Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм яклау бүлегенә өч эш көне эчендә әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**